Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлегенең Зирекле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«18» ноябрь 2023 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә узган: «Биляр-Озеро авыл җирлеге Зирекле авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Зирекле торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту, су үткәрү торбаларын салу белән чокырларны ремонтлау (сатып алу, ташу, салу);

урам яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 206 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 107 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 107 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлегенең Зирекле авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Биляр-Озеро авыл җирлеге Зирекле авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Зирекле торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту, су үткәрү торбаларын салу белән чокырларны ремонтлау (сатып алу, ташу, салу);

урам яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биляр-Озеро авыл җирлегенең Зирекле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.С. Оренбургов

Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы:: В.С.Оренбургов